# КАРАР

## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге составына керүче Чыбыклы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**16.11.2020** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 16 нче ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлегенең Чыбыклы авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- һәйкәлне төзекләндерү һәм ремонтлау (брусчатка җәю һәм 4 данә эскәмия кую);
- Кыр урамында балалар уен мәйданчыгы сатып алып урнаштыру, тирә-юнен төзекләндерү;
- балалар уен мәйданчыгына сатып алып, коймa кую (4 данә), төзекләндерү.
- зиратта чүп савыты (2 данә) кую өчен мәйданчык ясап, аны коймалау, төзекләндерү
- юлны ремонтлау (Совет урамына асфальт салу)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 386 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 200 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 157 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 43 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлегенең Чыбыклы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.
2. «Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлегенең Чыбыклы авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:
   - һәйкәлне төзекләндерү һәм ремонтлау (брусчатка җәю һәм 4 данә эскәмия кую);
   - Кыр урамында балалар уен мәйданчыгы сатып алып урнаштыру, тирә-юнен төзекләндерү;
   - балалар уен мәйданчыгына сатып алып, коймa кую (4 данә), төзекләндерү.
   - зиратта чүп савыты (2 данә) кую өчен мәйданчык ясап, аны коймалау, төзекләндерү
   - юлны ремонтлау (Совет урамына асфальт салу)
3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Чыбыклы авыл җирлеге башлыгы** **И.Н. Гадершин**